Reviews

Бәяләмә һәм күзәтүләр

Рецензии и обзоры

DOI: 10.26907/2311-2042-2025-25-2-174-179

# REVIEW OF THE COLLECTION OF WORKS "JOURNALISM BORN IN FLAMES" BY ALFIA SHAMOVA (KAZAN: TATAR KITAP NASHRIYATY, 2022, 247 P.)

**Golnara Fandasovna Zhamaletdinova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
gulnara.zamaletdinova@kpfu.ru.

**Nuriya Usmanovna Khaliullina,**
Bashkir State Pedagogical University n.a. M. Akmulla,
3-a Oktyabrskoj revoljucii Str., Ufa, 450077, Russian Federation,
nurkha@yandex.ru.

The article reviews the collection of works "Journalism Born in Flames (Ut echende tugan matbugat)", compiled by Alfiya Shamova. In this book, based on archival documents, the author provides an overview of the multifaceted work done by Tatar correspondent writers who brought the harsh truth about the events in the fronts of the Great Patriotic War to the entire Soviet people. The articles have supplementary illustrative material, which complements the work, providing an opportunity to get acquainted with front-line newspapers and front-line correspondents.

**Key words**: Tatar literature, Tatar writers, Great Patriotic War, Tatar military press

**For citation:** Zhamaletdinova, G., Khaliullina, N. Review of the collection of works "Journalism born in flames" by Alfia Shamova (Kazan: Tatar kitap nashriyaty, 2022, 247 p.) // Tatarica. 2025. № 2 (25). pp. 174–179. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-174-179

In the book "Journalism Born in Flames" ("Ut echende tugan matbugat"), Alfiya Shamova makes a wonderful review of the frontline newspapers published in the Tatar language. The collection includes poems, letters, and excerpts taken from the articles of Tatar writers and journalists. These sources cover the activities of Tatar frontline newspapers, and clearly show how our famous writers, living in the trenches, fought for the liberation of the Soviet country from Nazi fascists.

The collection is dedicated to the memory of the outstanding Tatar writer Afzal Shamov (1901–1990). The military commander Afzal Shamov was the only Tatar writer who went through three wars:

the Civil War, the Great Patriotic War and the Soviet-Japanese War. He went to all the three wars of his own volition. The writer captured seven fascists on June 30, 1944 during the operation "Bagration" in Belarus. For three years and six months Afzal Shamov contributed articles to frontline and military newspapers "The Forward to Defeat the Enemy!" and "The Suvorov Onslaught" (1943–1946).

In her interview, given to Intertat, Alfiya Shamova says that about twenty Tatar writers served as war correspondents during the war: "They were Khatib Gusman, Sharaf Mudarris, Shaykhi Mannur, Abdulla Akhmet, Akhmet Yerikey, Gali Huzhi, Akhmet Yunus, Riza Ishmuratov, Muhammad Sadri, Gusman Bakirov, Ibrahim Gazi, Akhmet Faizi, Gabdrakhman Absalyamov, Giz-Al-Gabid, Mahmoud Maksoud, Garif Galiyev, Gamir Nasri, Adel Kutui, and Munir Mazunov. In addition, another five writers – Gumer Bashirov, Fatih Husni, Mirsay Amir, Hassan Khayri, Gaziz Idelle, and the artist Baynazar Almanov – were on two-month creative business trips to frontline newspapers" [2]. According to the calculations of Afzal Shamov's daughter, during the Great Patriotic War, more than 600 articles of the writers were published in the frontline newspaper [2].

Alfiya Shamova began working on the collection of articles 35 years ago. She took as her testament the words of her father who wrote an article published in the Bulletin of Journalists of the USSR in 1989: "Years will pass, and historians will turn over the yellowed pages of our newspapers with excitement and, reading the smallest reports of our war correspondents, will say: 'What a noble, what a great feat they performed!' - and will pronounce their names with great respect". The author of the book uses these Afzal Shamov's words as an epigraph for her introduction.

Unfortunately, the activities of the mass media and war correspondents during the Great Patriotic War received little coverage in the post-war period. According to the data of the special project "Military Corps-Heroes" (2025), 4,500 military officers worked at the front and in the rear [3]. Eighty years have passed since the Victory in the Great Patriotic War, however the activities of the media during the war years and the work of war correspondents in particular have not received due attention so far.

Over the past 80 years, only two popular science publications, dedicated to the work of journalists at the fronts of the Great Patriotic War, were published nationwide: the book "Writers-Correspondents in the Fronts of the Great Patriotic War" by V. A. Shoshin [4] and the book-album "War Correspondents" by V. K. Gapon.

In the history of Tatar journalism, Gabdrakhman Apsalamov was the first to write on this topic. In 1947, the writer published an article entitled "Frontline Newspapers" [5] in the journal "Soviet Literature" under his military pseudonym (G. Kamalov). In 1984, the Tatar Book Publishing House released A. K. Ainedinov's book entitled "The Chronicle of Valor" [6] in Russian. According to A. Shamova, the author of the mentioned book, having reviewed the articles in 16 frontline newspapers, provided detailed information about their multifaceted themes. However, having analyzed all these frontline newspapers, the author only focused on about 60 materials that demonstrated the heroism of our compatriots. He devoted special attention to the role of the Party and Komsomol in the military units' feats" [1, p. 5].

In her introductory article, A. Shamova reviews five collections, published by Tatgosizdat, based on materials from Tatar front-line newspapers: "Vatan sugyshy geroilary - tatarlar" ("The Tatar Heroes of the Patriotic War") (1943) [7], "Nafrat koche" ("The Power of Hatred") (1944) [8], "Tonyak balkyshy" ("Northern Lights") (1944) [9], "Batyrlar kitaby" ("The Book of Heroes") (1945, 1947) [10],[11], "Zhinu yely" ("The Year of Victory") (1946, 1948) [12], [13].

While working on the collection, A. Shamova summarized the rich material stored in various archives:

1. *The Fund of the National Museum of the Republic of Tatarstan:* complete collections of the newspapers "Vatan ochen" ("The For the Motherland"), "Front hakyykate" ("The Front-line Truth"), "Zhinu bairagy" ("The Victory Banner"), individual issues of the newspapers "Alga, doshman ostena!" ("The Forward to Defeat the Enemy!") (1944–1945, a complete collection), "Front pravdasy" ("The Front-line Truth"), "Sovet sugyshchysy" ("The Soviet Warrior"), "Vatan namusy ochen" ("The For the Honor of the Motherland"), "Vatanny saklauda" ("The In Defense of the Motherland"), "Suvorovchy" ("The Suvorov's Follower"), "Kyzyl Armiya" ("The Red Army").

2. *State Archives of the Republic of Tatarstan*: Issue 19 of the newspaper "Trevoga" ("The Alarm") (August 9, 1944–August 2, 1945).

3. *Muhammad Sadri's personal archive:* a complete collection of the newspaper "Vatan

namusy ochen" ("The For the Honor of the Motherland").

4. *Afzal Shamov's personal archive:* individual issues of the newspapers "Vatannu saklauda" ("The In Defense of the Motherland") (a complete collection), "Alga, doshman ostena!" ("The Forward to Defeat the Enemy") (1942–1943, a complete collection; individual issues of 1944–1945), "Front hakyykate" ("The Front-line Truth") (39 issues), "Suvorovlarcha kysryklau" ("The Suvorov Onslaught") (2 issues), "Vatan ochen" ("The For the Motherland") (3 issues), "Zhinu bairagy" ("The Victory Banner") (1 issue).

5. *Gabdrakhman Apsalyamov's personal archive:* one issue of each of these newspapers: "Suvorovchy" ("The Suvorov's Follower"), "Trevoga" ("The Alarm") and "Vatan ochen sugyshka" ("The Fight for the Motherland") (reissued).

6. *Mirsai Amir's personal archive:* individual issues of the newspaper "The For the Motherland", one issue of each of these newspapers: "Sovet soldaty" ("The Soviet Soldier"), "Front hakyykate" ("The Front-line Truth") [8, p. 3].

The book, titled "Journalism Born in Flames", includes short excerpts from essays, articles, war episodes, leaflets, memoirs, travelogues, poems, stories, humorous works and letters by Tatar writers and journalists published in front-line newspapers. In addition, a wealth of photographic material is provided that reveals the book's content. All of these are chronologically arranged.

The book, compiled by A. Shamova, consists of two sections. The first section contains materials from 13 newspapers published during the Great Patriotic War [1, pp. 239–223]. The second section presents materials from three newspapers published during the Japanese War (1945) [1, pp. 224–235]. The appendix contains three materials: "Writers who served in front-line newspapers" [1, pp. 239–242], "Personalities who were on business trips" [1, pp. 243], "Information about front-line newspapers published in the Tatar language during the Great Patriotic War" [1, pp. 244].

Readers, having familiarized themselves with this book, can see that during the Great Patriotic War Tatar newspapers were published at the front, our famous writers who lived and worked in the trenches spared no effort to liberate the Soviet country from Hitler's fascists, that they overcame all the trials of the war and fulfilled their civic duty to the Motherland with honor. Their military service in bringing the Great Victory Day closer deserves the highest praise. With this book, A. Shamova has erected a monument to the Tatar writers who participated in the war.

**References**

1. Shamova, Ə. A. (2022). *Ut echende tugan matbugat: Boyek Vatan sugyshy chorynda tatar telende chykkan front gazetalary zhyyentugu* [Journalism Born in Flames: A Collection of Front-Line Newspapers Published in the Tatar Language During the Great Patriotic War]. 247 p. Kazan, Tatar kitap nashriyaty. (In Tatar)

2. Shamova, Ə. A. *"Əti – och sugyshta bulgan berdanber tatar yazuchysy" – Afzal Shamov turynda istaleklar* ["My Father Is the Only Tatar Writer Who Has Been through Three Wars" – memoirs about Afzal Shamov]. URL: https://intertat.tatar/news/ti-ch-sugyshta-bulgan-berd-nber-tatar-yazuchysy-afzal-shamov-turynda-ist-lekl-r?ysclid=mgejb9n8ie207778310. (In Tatar)

3. Shoshin, V. A. (2006). *Pisateli-korrespondenty na frontakh Velikoi Otechestvennoi voiny* [Writers-Correspondents on the Fronts of the Great Patriotic War]. 610 p. Moscow, Nauka. (In Russian)

4. Gapon, V. K. (2018). *Voennye korrespondenty* [War Correspondents]. 253 p. Moscow, Patriot. (In Russian)

5. Kamalov, G. (1947). *Front gazetalary* [Front-line Newspapers]. Sovet adabiyaty. No. 5, pp. 91–95. (In Tatar)

6. Ainetdinov, A. K. (1984). *Letopis' podviga: istoricheskii ocherk po stranitsam tatarskikh frontovykh gazet* [Chronicle of a Feat: A Historical Essay Based on the Tatar Frontline Newspapers]. 112 p. Kazan, Tatar. kn.izd. (In Russian)

7. *Vatan sugyshy geroilary - tatarlar* (1943) [Tatar Heroes of the Patriotic War]. Toz. A. Əhmət. 116 p. Kazan, Tatgosizdat. (In Tatar)

8. *Nafrat koche: Kalinin frontyndagy batyr tatar sugyshchylary ham ofitserlar turynda* (1944) [The Power of Hatred: About the Brave Tatar Soldiers and Officers in the Kalinin Front]. Toz. A. Shamov. 116 p. Kazan, Tatgosizdat. (In Tatar)

9. Apsalamov G. (1944). *Tonyak balkyshy* [Northern Lights]. 144 p. Kazan, Tatgosizdat. (In Tatar)

10. *Batyrlar kitaby: 1 kitap* (1945) [The Book of Heroes: Book 1]. 116 p. Kazan, Tatgosizdat. (In Tatar)

11. *Batyrlar kitaby: 2 kitap* (1947) [The Book of Heroes: Book 2]. 116 p. Kazan, Tatgosizdat. (In Tatar)

12. *Zhinu yely: Berenche Ukraina frontyndagy batyr tatar sugyshchylary ham ofitserlary turynda* (1946) [The Year of Victory: About the Brave Tatar Soldiers and Officers of the First Ukrainian Front]. Toz. G. Idelle. 116 p. Kazan, Tatar kitap nashriyaty. (In Tatar)

13. *Zhinu yely: Berenche Ukraina frontyndagy batyr tatar sugyshchylary ham ofitserlary turynda* (1948) [The Year of Victory: About the Brave Tatar Soldiers and Officers of the First Ukrainian Front]. Toz. G. Idelle. 116 p. Kazan, Tatar kitap nashriyaty. (In Tatar)

# ӘЛФИЯ ШАМОВА ТӨЗЕГӘН «УТ ЭЧЕНДӘ ТУГАН МАТБУГАТ» ИСЕМЛЕ ҖЫЕНТЫККА (КАЗАН: ТАТАР. КИТ. НӘШР. 2022, 247 Б.) БӘЯЛӘМӘ

**Гөлнара Фәндәс кызы Җамалетдинова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 йорт,
gulnara.zamaletdinova@kpfu.ru.

**Нурия Усман кызы Хәлиуллина,**
М. Акмулла исемендәгә Башкорт дәүләт педагогия университеты,
Россия, 450077, Уфа ш., Октябрь революциясе ур., 3-а йорт,
nurkha@yandex.ru.

Мәкаләдә Әлфия Шамова төзегән «Ут эчендә туган матбугат» җыентыгы бәяләнелә. Әлеге китапта автор, архив документларына нигезләнеп, Бөек Ватан сугышы фронтларында булган вакыйгалар турындагы кырыс хакыйкатьне бөтен Совет халкына җиткергән татар язучы-корреспондентларының күпкырлы эшләренә күзәтү ясый. Җыентыктагы мәкаләләргә кагылышлы иллюстратив материал булу хезмәтне тагы да тулыландыра, фронтта басылып чыккан газеталар, фронт корреспондентлары белән танышу мөмкинлеге бирә.

**Төп төшенчәләр:** татар әдәбияты, татар язучылары, Бөек Ватан сугышы, татар хәрби матбугаты

**Сылтама өчен:** Җамалетдинова Г. Ф., Хәлиуллина Н. У. Әлфия Шамова төзегән «Ут эчендә туган матбугат» исемле җыентыкка (Казан: Татар. кит. нәшр. 2022, 247 б.) бәяләмә // Tatarica. 2025. № 2 (25). 174–179 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-174-179

«Ут эчендә матбугат» китабында татар телендә чыккан фронт газеталарына Әлфия Шамова тарафыннан искиткеч бай күзәтү ясалган. Җыентыкта татар язучылары һәм журналистларының мәкаләләреннән өзекләр, шигырьләр, хатлар урын алган. Әлеге чыганаклар фронтта чыккан татар газеталарының эшчәнлеген яктырта, окопларда яшәп иҗат иткән мәшһүр язучыларыбыз Совет илен Гитлер фашистларыннан азат итү өчен ничек көрәшкәннәрен ачык күрсәтә.

Җыентыкны автор этисе – күренекле татар язучысы Афзал Шамов (1901–1990) истәлегенә багышлый. Военкор Афзал Шамов – өч сугышны узган бердәнбер татар язучысы, Гражданнар сугышы, Бөек Ватан һәм совет-япон сугышларын кичкән шәхес. Өчесенә дә ул үз теләге белән киткән. Язучы 1944 елның 30 июнендә Белоруссиядә тарихта билгеле булган «Багратион» операциясе вакытында җиде немецны әсирлеккә алган. Афзал Шамов өч ел ярым дәвамында «Алга, дошман өстенә!», «Суворовча кысрыклау» исемле фронт һәм хәрби газеталарында эшләгән (1943-1946). Ә.А. Шамова исәпләп чыгарганча, язучының Бөек Ватан сугышы елларында фронт газетасында 600 дән артык язмасы чыккан [2].

Әлфия Шамова Интертатка биргән интервьюсында егермеләп татар язучысы сугыш чорында хәрби корреспондент булып хезмәт иткәне турында сөйли: «Болар Хатыйп Госман, Шәрәф Мөдәррис, Шәйхи Маннур, Абдулла Әхмәт, Әхмәт Ерикәй, Гали Хуҗи, Әхмәт Юныс, Риза Ишморат, Мөхәммәт Садри, Госман Бакиров, Ибраһим Гази, Әхмәт Фәйзи, Габдрахман Әпсәләмов, Гыйз-әл-Габид, Мәхмүд Максуд, Гариф Галиев, Гамир Насрый, Гадел Кутуй, Мөнир Мазунов. Болардан тыш биш язучы – Гомәр Бәширов, Фатих Хөсни, Мирсәй Әмир, Хәсән Хәйри, Газиз Иделле һәм рәссам Байназар Әлмәнов фронт газеталарында ике айлык иҗади командировкада була» [2].

Әлфия Шамова җыентыкны 35 ел элек эшли башлаган. Ул этисенең 1989 елгы СССР журналистлары бюллетенендә басылган мәкаләсендәге «Еллар үтәр, тарихчылар безнең газетабызның саргайган битләрен дулкынланып актарыр һәм хәрби корреспондентларыбызның

иң кечкенә генә хәбәрләрен укып та: – Нинди изге, нинди бөек эш эшләгәннәр! – дип, аларның исемнәрен бик зур хөрмәт белән телгә алыр» дигән сүзләрне васыять итеп кабул иткән [1]. Бу юлларны автор үзенең кереш сүзе өчен эпиграф буларак куллана.

Бөек Ватан сугышы елларында массакүләм мәгълүмат чараларының һәм хәрби корреспондентларның эшчәнлеге сугыштан соңгы чорда, кызганычка каршы, аз яктыртылган. «Герои военкоры» (2025) махсус проекты мәгълүматлары буенча, фронтта һәм тылда 4,5 мең военкор эшләгән [3]. 80 ел эчендә гомумроссия масштабында журналистларның Бөек Ватан сугышы фронтларындагы эшләренә багышланган ике генә фәнни-популяр басма дөнья күргән: В.А. Шошинның «Бөек Ватан сугышы фронтларындагы язучы-корреспондентлар» китабы [4] һәм В.К. Гапонның «Хәрби корреспондентлар» исемле альбом-китабы.

Татар журналистикасы тарихында бу теманы башлап җибәрүче дип Габдрахман Әпсәламов санала. Язучы 1947 елда «Фронт газеталары» исемле мәкаләсен «Совет әдәбияты» журналында сугыш чорындагы әдәби тәхәллүсе (Г. Камалов) белән бастырып чыгара [5]. 1984 елда Татарстан китап нәшриятында А.К. Айнединовның «Летопись подвига» исемле китабы рус телендә дөнья күрә [6]. Ә. Шамова фаразлавынча, китапның авторы, 16 фронт газетасы сәхифәләре буенча сәяхәт кылып, алар турында тулырак мәгълүмат бирә һәм газеталарның күпьяклы тематикасын ачып күрсәтә. Ләкин автор фронт газеталарын анализлау барышында якташларыбызның батырлыгына багышланган 60 ка якын материалны гына күрсәтә. Аерым игътибарны ул партия һәм комсомолның хәрби подразделениеләрдәге роленә бирә [1, б. 5].

Ә. Шамованың кереш мәкаләсендә татар фронт газеталары материаллары буенча Татгосиздат чыгарган 5 җыентык анализлана: «Ватан сугышы геройлары – татарлар» (1943) [7], «Нәфрәт көче» (1944) [8], «Төньяк балкышы» (1944) [9], «Батырлар китабы» (1945, 1947) [10], [11], «Җиңү елы» (1946, 1948) [12], [13].

Җыентыкны төзү барышында Ә. Шамова төрле архивларда сакланган бай материалны гомумиләштергән:

1. *Татарстан Республикасы Милли музее фонды:* «Ватан өчен», «Фронт хакыйкате», «Җиңү байрагы» газеталарының тулы төпләмәләре, «Алга дошман өстенә» (1944-1945 еллар, тулы төпләмәсе), «Фронт правдасы», «Совет сугышчысы», «Ватан намусы өчен», «Ватанны саклауда», «Суворовчы», «Кызыл Армия» газеталарының аерым саннары.
2. *Татарстан Республикасы Дәүләт архивы:* «Тревога» газетасының 19 саны (1944, 9 август – 1945, 2 август).
3. *Мөхәммәт Садриның шәхси архивы:* «Ватан намусы өчен» газетасының тулы төпләмәсе.
4. *Афзал Шамовның шәхси архивы:* «Ватанны саклауда» (тулы төпләмә), «Алга дошман өстенә» (1942-1943 елларның тулы төпләмәсе; 1944-1945 елларның аерым саннары), «Фронт хакыйкате» (39 сан), «Суворовча кысырыклау» (2 сан), «Ватан өчен» (3 сан), «Җиңү байрагы» (1 сан) газеталарының аерым саннары.
5. *Габдрахман Әпсәләмовның шәхси архивы:* «Суворовчы», «Тревога» һәм «Ватан өчен сугышка» (новодел) исемле газеталарның берәр саны.
6. *Мирсәй Әмирнең шәхси архивы:* «Ватан өчен» газетасының аерым саннары, «Совет сугышчысы» һәм «Фронт хакыйкате» газеталарының берәр саны [8, 3 б.].

«Ут эчендә туган матбугат» исемендәге китапка татар язучылары һәм журналистларының фронт газеталарында басылган очеркларыннан, язмаларыннан, мәкаләләреннән, сугыш эпизодларыннан, листовкалардан, истәлекләрдән, юлъязмалардан, шигырьләреннән, хикәяләреннән, юмор әсәрләреннән һәм хатлардан кыска өзекләр кертелгән. Моннан тыш, китап эчтәлеген ачкан бай фотоматериал да бирелгән. Алар барысы да хронология буенча урнаштырылган.

Ә. Шамова төзегән китап ике бүлектән тора. Беренче бүлектә Бөек Ватан сугышы чорында чыккан 13 газетада булган мәгълүматлар китерелә [1, б. 239-223], ә икенче бүлек Япон сугышы (1945) чорындагы 3 газета материалларыннан тора [1, б. 224-235]. Кушымтада түбәндәгеләр урын ала: «Фронт газеталарында хезмәт иткән язучылар» исемлеге [1, б. 239-242], «Командировкада булган шәхесләр» [1, б. 243], «Бөек Ватан сугышы елларында татар телендә чыккан фронт газеталары турында белешмә» [1, б. 244].

Бу китап белән танышу барышында укучылар, Бөек Ватан сугышы чорында фронтта чыккан татар газеталары хакында мәгълүмат алалар, окопларда яшәп иҗат иткән

мәшһүр язучыларыбызның Совет илен Гитлер фашистларыннан азат итү өчен көчләрен кызганмыйча, сугышның бөтен сынауларын үтеп, үзләренең гражданлык бурычларын Ватан алдында намус белән үтәгәннәрен күрәләр. Бөек Җиңү көнен якынайтуда аларның сугышчан хезмәтләре иң югары бәягә лаек. Әлеге китабы белән Ә. Шамова сугышта катнашкан татар язучыларына һәйкәл куйган.

**Әдәбият**

1. *Шамова Ә.А.* Ут эчендә туган матбугат: Бөек Ватан сугышы чорында татар телендә чыккан фронт газеталары җыентыгы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2022. 247 б.

2. *Шамова Ә.А.* «Әти – өч сугышта булган бердәнбер татар язучысы» – Афзал Шамов турында истәлекләр // URL: https://intertat.tatar/news/ti-ch-sugyshta-bulgan-berd-nber-tatar-yazuchysy-afzal-shamov-turynda-ist-lekl-r?ysclid=mgejb9n8ie 207778310

3. *Шошин В.А.* Писатели-корреспонденты на фронтах Великой Отечественной войны. М.: Издательство «Наука», 2006. 610 с.

4. *Гапон В.К.* Военные корреспонденты. М.: Издательство «Патриот», 2018. 253 с.

5. *Камалов Г.* Фронт газеталары // Совет әдәбияты. 1947. №5. 91-95 б.

*6. Айнетдинов А. К.* Летопись подвига: исторический очерк по страницам татарских фронтовых газет. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 112 с.

7. Ватан сугышы геройлары – татарлар / төз. А. Әхмәт. Казан: Таттосиздат, 1943. 116 б.

8. Нәфрәт көче: Калинин фронттындагы батыр татар сугышчылары һәм офицерлары турында / төз. А. Шамов. Казан: Таттосиздат, 1944. 116 б.

9. Әпсәләмов Г. Төньяк балкышы. Казан: Таттосиздат, 1944. 144 б.

10. Батырлар китабы: 1 китап. Казан: Таттосиздат, 1945. 116 б.

11. Батырлар китабы: 2 китап. Казан: Таттосиздат, 1947. 116 б.

12. Җиңү елы: Беренче Украина фронтындагы батыр татар сугышчылары һәм офицерлары турында / төз. Г. Иделле. Казан: Татар. кит. нәшр., 1946. 116 б.

13. Җиңү елы: Беренче Украина фронтындагы батыр татар сугышчылары һәм офицерлары турында / төз. Г. Иделле. Казан: Татар. кит. нәшр., 1948. 116 б.

---

# РЕЦЕНЗИЯ НА СБОРНИК АЛЬФИИ ШАМОВОЙ «ПЕЧАТЬ, РОЖДЕННАЯ В ОГНЕ» (КАЗАНЬ: ТАТАР. КН. ИЗД-ВО. 2022, 247 С.)

**Гульнара Фандасовна Замалетдинова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
gulnara.zamaletdinova@kpfu.ru.

**Нурия Усмановна Халиуллина**,
Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы,
Россия, 450077, г. Уфа, ул. Октябрьской революции, д. 3-а,
sovet.rus16@gmail.com.

В статье анализируется сборник Альфии Шамовой «Ут эчендә туган матбугат» («Печать, рожденная в огне»). Автор на основе богатого архивного материала реконструирует многогранную деятельность военных корреспондентов на фронтах Великой Отечественной войны.

**Ключевые слова:** татарская литература, татарские писатели, Великая Отечественная война, татарские военные газеты

**Для цитирования**: Замалетдинова Г. Ф., Халиуллина Н. У. Рецензия на сборник Альфии Шамовой «Печать, рожденная в огне» (Казань: Татар. кн. изд-во. 2022, 247 с.) // Tatarica. 2025. № 2 (25). С. 174–179. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-174-179